ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 май 2025 ел № 3723

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Сөембикә, Чулман, Автозаводский, Яшьлек проспектлары буенча җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру проектын раслау турында

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатында һәм «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, шәһәр Уставының 41 статьясындагы 9 өлешнең 24.1 пунктчасы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Сөембикә, Чулман, Автозаводский, Яшьлек проспектлары буенча җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру проектын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә әлеге карарны, «Интернет» челтәрендә ведомствоның рәсми сайтында урнаштыру өчен, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына җибәрергә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.


4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.


Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов


Башкарма комитетның
2025 елның 23 маендагы
3723 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
Сөембикә, Чулман, Автозаводский, Яшьлек проспектлары буенча
җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру проекты




СХЕМА ОРГАНИЗАЦИИ ДОРОЖНОГО ДВИЖЕНИЯ
проспект Сююмбике


СХЕМА ОРГАНИЗАЦИИ ДОРОЖНОГО ДВИЖЕНИЯ
проспект Сююмбике
(участок от проспекта Дружбы Народов до ул. Татарстан)


СХЕМА ОРГАНИЗАЦИИ ДОРОЖНОГО ДВИЖЕНИЯ
(участок от проспекта Дружбы Народов






СХЕМА ОРГАНИЗАЦИИ ДОРОЖНОГО ДВИЖЕНИЯ
проспект Сююмбике
(участок от проспекта Дружбы Народов до ул. Татарстан)


СХЕМА ОРГАНИЗАЦИИ ДОРОЖНОГО ДВИЖЕНИЯ
проспект Сююмбике
(участок от проспекта Дружбы Народов до ул. Татарстан)






СХЕМА ОРГАНИЗАЦИИ ДОРОЖНОГО ДВИЖЕНИЯ
проспект Энгельса
(участок от ул. Машиностроительная до пр-та Мира)


СХЕМА ОРГАНИЗАЦИИ ДОРОЖНОГО ДВИЖЕНИЯ
проспект Яшьлек
участок от ул. Машиностроительная до пр-та Мира


СХЕМА ОРГАНИЗАЦИИ ДОРОЖНОГО ДВИЖЕНИЯ


СХЕМА ОРГАНИЗАЦИИ ДОРОЖНОГО ДВИЖЕНИЯ


СХЕМА ОРГАНИЗАЦИИ ДОРОЖНОГО ДВИЖЕНИЯ
проспект Автозаводский
(участок от пр-та Сююмбике до ул. Машиностроительная)




Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева